РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 26 августы № 32

Түбән Кама шәһәр Советының
кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләрнең вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган күләмнәрдә һәм нигезләр буенча түләүләр башкарылырга мөмкин.

Күрсәтелгән килешүдә каралган бер тапкыр бирелә торган түләү даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның эшкә кабул ителгәннән соң унбер айдан да иртәрәк булмаган шәхси гаризасы нигезендә башкарыла.»;

2. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре бюджет өлкәсенең Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 40 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җитәкчеләргә, белгечләргә, хезмәткәрләргә һәм эшчеләргә Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләрнең вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган күләмнәрдә һәм нигезләр буенча түләүләр башкарылырга мөмкин.

Күрсәтелгән килешүдә каралган бер тапкыр бирелә торган түләү җитәкче, белгеч, хезмәткәр яки эшченең эшкә кабул ителгәннән соң унбер айдан да иртәрәк булмаган шәхси гаризасы нигезендә башкарыла.»;

3. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә аерым муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны премияләү буенча Түбән Кама шәһәре Мэры каршындагы комиссия турында» 2021 елның 18 ноябрендәге 62 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә аерым муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны

премиялəү буенча Түбəн Кама шəһəре Мэры каршындагы комиссия турында нигезлəмəнең 3 пунктына түбəндəге эчтəлекле абзац өстəргə:

«- аерым муниципаль вазыйфаларны билəүче затларга бер тапкыр бирелə торган түлəүлəр, матди ярдəм һəм мондый түлəүлəр күлəме турында карарлар кабул итү.».

4. Əлеге карарның 3 пункты үз гамəлен 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгəн мөнəсəбəтлəргə тарата.

5. Җəмəгатьчелек һəм массакүлəм мəгълүмат чаралары белəн элемтə бүлегенə əлеге карарны Түбəн Кама шəһəре Уставы белəн билгелəнгəн тəртиптə бастырып чыгарырга, шулай ук Түбəн Кама муниципаль районының рəсми сайтында «Интернет» мəгълүмат-телекоммуникация челтəрендə урнаштырырга.

6. Карарның үтəлешен контрольдə тотуны Түбəн Кама шəһəре Мэры урынбасары М. В. Камелинага йөклəргə.

Түбəн Кама шəһəре
Мэры вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В. Камелина